| МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.08.2014 07-80

Казан ш.

**Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру хакында**

“Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр бюджетларына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 22.11.2013 ел, №909 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

1. Кушымта нигезендә, башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибен расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Ю.И.Абдреевага, министр урынбасары А.Л.Анфимовага йөкләргә.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
18.08.2014 ел, №07-80
боерыгына кушымта

**Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру**

**ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип муниципаль берәмлекләрнең (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары тарафыннан “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр бюджетларына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 22.11.2013 ел, №909 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап (алга таба – хисап) тапшыру кагыйдәләрен, срокларын һәм формаларын билгели.

2. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тиешле муниципаль район составына кергән, үзенә башка бюджетара трансфертлар средстволары бирелгән һәр муниципаль берәмлек буенча муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тапшыра.

3. Муниципаль районнарның (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары хисапны кәгазьдә (бер үк вакытта “БАРС Web-Своды” программасында эшләнгән электрон рәвештәге күчермәсе белән) тапшыра. Шул ук вакытта хисапның төп нөсхәсе һәм күчермәсе эчтәлеге ягыннан бер үк төрле булырга тиеш. Хисап агымдагы (хисап) финанс елының 1 апреленә, 1 июленә, 1 октябренә, шулай ук хисап финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына бу Тәртипкә кушымта нигезендә төзелә һәм квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 нче числосыннан да соңга калмыйча, тапшырыла.

4. Кәгазьдәге хисапка эш башкаручы (вазыйфасын, элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтеп) муниципаль берәмлекнең финанс органы җитәкчесе, муниципаль берәмлек башлыгы кул куя (ФИО тулысынча

күрсәтеп), ахырда кул кую датасы күрсәтелә һәм әлеге органның мөхере сугыла.

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
18.08.2014 ел, №07-80
боерыгы белән расланган
Башка бюджетара
трансфертлардан
файдалану турында
хисап тапшыру тәртибенә
кушымта

Форма

20__елның 1____нә

“Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр бюджетларына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 22.11.2013 ел, №909 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торучы ___________________________________(муниципаль берәмлек атамасы) бюджеты чыгымнары турында хисап

| | |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары турында хисапны формалаштыручы финанс органы атамасы | |

Үлчәү берәмлеге: сумнарда.

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торучы средстволарның хәрәкәте

| Күрсәткеч атамасы | Сумма | |
|---|---|---|
| | хисап кварталы өчен | ел башыннан үсеп баручы йомгак белән |
| 1 | 3 | 4 |
| Хисап елы башына калдык, барлыгы | Х | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗы расланган | Х | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | Х | |
| Хисап кварталы башына калдык, барлыгы | | Х |
| шул исәптән:<br>ТатарстанРеспубликасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | | Х |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган средстволар, барлыгы | | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗы расланган, ел башына калдык | | |
| агымдагы елга күздә тотылган | | |
| Башка бюджетара трансфертлар средстволары хисабына муниципаль берәмлек тоткан средстволар (кааса чыгымы) | | |
| шул исәптән:<br>узган елларда кире кайтарылган средстволар хисабына тотылган | | |
| агымдагы елга күздә тотылган средстволар хисабына тотылган | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылган, барлыгы | | |
| шул исәптән:<br>файдаланылмаган средстволар калдыгы | | |
| үзенә ихтыяж булмаган агымдагы ел калдыгы | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына түләтелгән | | |

| | | |
|---|---|---|
| Хисап кварталы (елы) ахырына калдык, барлыгы | | |
| шул исәптән:<br>чираттагы финанс елына ихтыяҗы расланган | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | | |

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар хисабына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын үтәү турында мәгълүматлар

Үлчәү берәмлеге: сумнарда.

| N п/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәлә коды* | Чара | Касса чыгымы, барлыгы | Шул исәптән: | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гражданнарның үзара салым средстволары | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Барлыгы | | | | | |

Муниципаль берәмлек
башлыгы
_______________/___________________________/
(имза) (тулы имза)
М.У.

Муниципаль берәмлекнең финанс
органы җитәкчесе
_____________/_______________________/
(имза) (тулы имза)

Эш башкаручы ____________ _________ _____________________ _________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (код белән телефон)
"__" _____________ 20__ ел

*- “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14,15,16 статьяларының 1 өлешендәге пункты номерына т